**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«04» октябрь 2016 ел** **№35**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум уздыруны инициацияләү турында” 2016 елның 30 сентябрендәге 28 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 декабрендәге 33-ТРЗ номерлы карары нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының “Яңа Кенәр референдумын үткәрү турында” 2016 елның 30 февралендәге 33-ТРЗ номерлы карары нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге уставының 12 статьясы:

1. 2016 елның 20 ноябренә Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга: «2017 елда үзара салым кертүгә Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә килешеп торасызмы, моңа 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Чернобыль АЭСында авария ябылуда катнашучылар 225 сум түләүләр күләме һәм җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән түбәндәге эшләрне башкару буенча:

-торак пунктларда юлларга вак таш түшәү: Яңа Кенәр авылы, Яңа Ашыт авылы, Шурабаш авылы., Шура авылы., Байкал авылы, Яңа Сәрдә авылы, Сөрде авылы, Югары Оры авылы, Түбән Оры авылы, Кызыл Яр авылы;

- мотопомпа сатып алу. Шурабаш авылы., Сөрде авылы;

- Яңа Кенәр авылындагы спорт мәйданчыгы төзү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе　　　　　　　　　　юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 йорт; ТР, Арча районы, Сөрде авылы, Совет ур., 48 й. ТР, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин ур., 17 й.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы　　　　Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ